**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 4220
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№2** **«31» января 2020 г.**

## 2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон,«2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29 январь 2020 елның 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 15 пункты нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 нче февраль көненнән алып Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта, гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын 6124,86 сум күлмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2019 елның 14 март 8 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Алан авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Хаҗиев

Теләче муниципаль районы
Алан авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
1нче номерлы кушымта
«31» гыйнварь 2020 ел №2

2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2500,0 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка ташу, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 844,86 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2780,0 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Теләче муниципаль районы
Алан авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
2нче номерлы кушымта
«31» гыйнварь 2020 ел №2

2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Тәнне кәфенләү | 1300,0 |
| 3.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 1200,0 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка ташу, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 844,86 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2780,0 |
| Барлыгы | 6124,86 |